| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кудашевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кодаш авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2023 Кодаш авылы № 2

Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең
Кодаш торак пунктында гражданнарның
үзара салым чараларын кертү һәм куллану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьяларына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясына ярашлы рәвештә, Кодаш авыл җирлеге башлыгы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы:

1.2023 елның 22 ноябренә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең Биектау авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым чараларын кертүгә ризамы һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
1. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучы якташларына һәйкәлне реконструкцияләү; трактор өчен асмалы җиһазлар (косилка) сатып алу).

2. Ремонт, коймалар төзү, зират коймаларын төзекләндерү.
3. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасы өчен тирән насослар һәм материаллар сатып алу, Кудаш авылында суүткәргеч ремонтлау).
4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (запас частьләр сатып алу; янгын сүндерү автомашинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү).
5. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту; үлән кырку; дизель ягулыгы сатып алу; трактор йөртүчегә килешү буенча хезмәт хакы).

“РИЗА” «КАРШЫ»

3.Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кодаш авылы, Тукай урамы, 54 нче йорт, авыл клубы адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.
4.Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә
6. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М. ШАКИРОВ